| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**12.12.2023** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3985** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 елның 02 ноябрендәге 2748 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 елның 02 ноябрендәге 2748 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) (2022 елның 26 гыйнварындагы 123 номерлы, 2022 елның 04 апрелендәге 761 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 3592 номерлы, 2023 елның 26 гыйнварындагы 101 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 нче таблицасы 1 нче графасында «Техник укыту бүлекләре (бюролары), җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре» юлындагы «министрлыкларның (ведомстволарның)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга.

2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлегенә «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин